**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлегенең Юлтимер авылы торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

**2025 елның 11 ноябре** **№ 2**

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, 28.07.2004 45-РТЗ Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Юлтимер авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Юлтимер авылы торак пунктында “I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт һәм контракт буенча узучы хезмәткәрләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:
- Юлтимер авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

2. Юлтимер торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Юлтимер авылында Яңа, Тау, Яр буе,Үзәк, урамы буенча юлларны ремонтлау ( махсус техника арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, таш ташу һәм вак таш җәю, юл өслеген тигезләү).

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү:
- ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары һәм Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Беларусь МТЗ-82.1 тракторына , ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары өчен запас частьләр сатып алу;
- Юлтимер авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4. Санкциясез чүплекләрне бетерү:
- Юлтимер авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп чар җыелу урыннарын чистарту (махсус техника арендалау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Азалак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында
рәислек итүче: И.Г.Габдулгазизов